**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет муниципального образования «поселок городского типа Актюбинский» Азнакаевского муниципального района**

ул. Губкина, д. 24, п.г.т.
Актюбинский, Азнакаевский
муниципальный район, 423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты**

Губкин урамы, 24 йорт, Актүбә ш.т.п.,
Азнакай муниципаль районы, 423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» июль 2023 ел № 85

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советының 2022 елның 15 декабрендәге 55 номерлы карары белән расланган (30.03.2023 №18 карар редакциядә), Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга таянып, «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенең 2023 елның 26 июльнең бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселок" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советының 2022 елның 15 декабрендәге 55 номерлы карары белән расланган (30.03.2023 №18 карар редакциядә), Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә:

- инженерлык инфраструктурасының территориаль зонасы (И) № 4-1 исемен И (И-Ф) зонасы регламентына ярашлы рәвештә җирләрне чынлыкта куллану территориясенә үзгәртергә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселок" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш

кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү тәртибен һәм вакытларын билгеләргә (кушымта).

3. Әлеге карарны Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.М. Курбиев

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ "ПОСЕЛОК ГОРОДСКОГО ТИПА АКТЮБИНСКИЙ" АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына кушымта
«27» июль 2023 ел № 85

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү эшләрен үткәрү тәртибе һәм сроклары**

| № | Эшләр уздыру тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү эшләрен оештыру. | 2023 елның II кварталы |
| 2.<br>2.1.<br>2.2. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең картографик материалларына үзгәрешләр кертү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны килештерүдә катнашучы хезмәтләр һәм ведомстволар кисәтүләренә шәрехләр әзерләү. | 2023 елның II кварталы |
| 3.<br>3.1.<br>3.2.<br>3.3.<br>3.4. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча фикер алышу.<br>Ачык тыңлаулар үткәрү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында закон проектына үзгәрешләр кертү.<br>Күрсәтелгән проектны һәм аңа карата мәҗбүри кушымталарны (беркетмә һәм ачык тыңлаулар бәяләмәсе) Башкарма комитет җитәкчесенә тапшыру.<br>Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге башлыгына җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә һәм аңа карата мәҗбүри кушымталарга үзгәрешләр кертү турында (беркетмә һәм ачык тыңлаулар бәяләмәсе) проектны Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советына раслау яисә кире кагу турында карар кабул итү өчен, аны кабат тапшыру датасын күрсәтеп, эшләп бетерергә җибәрү. | 2023 елның II кварталы |